| СОВЕТ<br>СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 октябрь 2019 ел. Иске-Тәрбит авылы № 23

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең Камыллы торак пунктында гражданнардан үзара салым акчалары җыю һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә туры китереп Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге карар кабул итте:

1.2019 елның 5 октябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Камыллы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Камыллы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- а) җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

« ӨЧЕН» “ КАРШЫ »

3. Әлеге карарны Иске Тәрбит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Тәрбит авыл җирлеге башлыгы В. Г. Тимофеев